| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>ЯЛКЫНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ЯЛКЫН<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30 октября 2019 года д.Ялкын № 6

ә

**Алексеевского муниципаль районының**
**“Ялкын җирлеге территориясендәге Караваево авылында**
**үзара салым кертү һәм гражданнарның үзара салым акчаларыннан**
**файдалану мәсьәләсе буенча**
**гражданнар җыенын билгеләү турында “**

06.10.2003 ел, № 131-ФЗ” Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында “Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында " 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы» , Алексеевск муниципаль районы Ялкын авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә,

**Карар бирәм:**

1. Алексеевск муниципаль районының Ялкын җирлеге территориясендәге Караваево авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча 2019 елның 13 нче ноябре көнне 16сәг 00 минутта гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:
Алексеевск муниципаль районы Ялкын җирлеге территориясендәге Караваево авылында 20 19 елда 300 сум күләмендә үзара салым кертелүгә,үзара салымны ,барлык шул җирлек территориясендә теркәлгән,балигъ булган затлардан, хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар ,1 нче төркем инвалидлардан, көндезге уку бүлеге студентларыннан тыш, җыюга һәм акчаларны җирле түбәндәге мәсәләләрне хәл итүгә тотуга сез ризамы?

-балалар уен мәйданчыгын төзекләндерү;

- контейнер мәйданчыклары урнаштыру ;

-җирлек эчендәге юлларны карап тоту һәм ремонтлау;

- торак пунктларның урамнарын карап тоту һәм төзекләндерү. “ӘЙЕ “ КАРШЫ”

3.Халык җыенын оештыручы итеп Алексеевск муниципаль районы Ялкын авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

4.Җыенның үткәрү урыны дип авыл мәдәният йортын билгеләргә.Адресы: Татарстан Республикасы.Алексеевск районы,Караваево авылы,Мәктәп урамы, 3 йорт

5.Әлеге карарны Караваево авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Караваево авыл җирлеге Советы бинасында мәгълүмат стендында урнаштырырга.

6. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Алексеевск муниципаль районы**
**Ялкын авыл җирлеге башлыгы**
**Совет Рәисе** **И.В.Гущина**